| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
| --- | --- | --- |
| Совет Менделеевского муниципального района | | Менделеевск муниципаль районы Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.12.2021 ел Менделеевск ш. № 98

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары нигезендә 2021 нче елның 26 нчы ноябрендәге Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән килешмәү турындагы килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2020 елның 21 апрелендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын расларга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм расланган документны Россия Федерациясенең Федераль территориаль планлаштыру дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының икътисад, сәнәгать, торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш һәм элемтә мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева